**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Киекле ав. **КАРАР**

«21» октября 2022 г. № 7

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елның 4 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Заречная урамы, 3А адресы буенча урнашкан Киекле авылы Күпфункцияле үзәге бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Заречная, Родниковая, Космонавтлар урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2022 елның 4 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Сәүдә урамы, 19 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Торговая, Молодежная, Олимпийская, Рабочая урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын икенче этабын уздыруны билгеләргә.
3. 2022 елның 4 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Совет урамы, 44 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Советская, Садовая, Солнечная, Школьная урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын өченче этабын уздыруны билгеләргә.
4. 2022 елның 4 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Комсомол урамы, 6 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Комсомольская, З. Каримова, Колхозная, Луговая урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. 2022 елның 4 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Заозерная урамы, 5 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Заозерная,

Сибирская урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын бишенче этабын уздыруны билгеләргә.

6. 2022 елның 4 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Нижняя урамы, 4 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын алтынчы этабын уздыруны билгеләргә.

2. Киекле авылында яшәүче гражданнар өчен гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толкалган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Халыкны эчә торган су белән тәэмин итү максатыннан, яңа сууткәргечләр үткәрү буенча төзү-монтаж эшләрен башкару өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу, су челтәрләрен ремонтлау, сууткәргеч челтәрләрен реконструкцияләүгә кирәкле товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком, кулланылган асфальт җәю (сатып алу, ташу, җәю), чокырларны ремонтлау (юеш коелган асфальт);

- Киекле авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

авыл җирлегенең торак пунктларындагы урамнарны, территорияләрне, Киекле авылындагы ике зиратны төзекләндерү һәм сезонлы карап тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үләнне чабу, коймаларны буяу);

- Киекле авылында спорт-массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм уздыру өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Киекле авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу;

- Киекле авылында халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы Л.И. Кашапова